**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы**

К А Р А Р

**№ 13** **Кәрәкәшле ав.** **«22» май 2015 ел**

**Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле**
**авыл җирлегенең 2014 елның 20 ноябрендәге**
**«Җир салымы турында»гы 21 санлы карарына**
**үзгәрешләр кертү турында** (2015 елның 27 апрелендәге
11 санлы карар редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының II өлешенең 31 бүлегенең 387 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы **карар бирә:**

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең 2014 елның 20 ноябрендәге «Җир салымы турында»гы 21 санлы карарына (27.04.2015 ел, № 11 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

"Салым ташламалары" турындагы 3 маддәдә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә игълан итәргә:

«1. Кадастр бәясеннән ташламалы салым ставкасын:

1) Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджеттан финанслана торган казна, автоном, бюджет учреждениеләре, идарә органнары тарафыннан биләнгән һәм салым салу объектлары дип танылган җир кишәрлекләренә карата 0,2% ;

2) 1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир участокларына карата 0,05%.

2. Әлеге карарны:

2.1. административ бинаның мәгълүмати стендында һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

2.2. Россия Федерациясе Салым кодексының I өлешендәге 5 маддәсенең 3 һәм 4 пунктларына ярашлы рәвештә, 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев